# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О квотировании и резервировании рабочих мест для инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
14 июля 2022 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 24 июля 2006 года № 60-ЗРТ «О квотировании и резервировании рабочих мест для инвалидов и граждан, особо нуждающихся в социальной защите» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 7 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 7; 2014, № 6 (I часть), № 6 (II часть), № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I); 2021, № 93 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 3:
а) часть 1 изложить в следующей редакции:
«1. Квота для приема на работу инвалидов устанавливается для работодателей, осуществляющих деятельность на территории Республики Татарстан, в следующих размерах:
1) для работодателей, численность работников которых составляет от 35 человек до 100 человек включительно, – в размере 2 процентов от среднесписочной численности работников;
2) для работодателей, численность работников которых превышает 100 человек, – в размере 3 процентов от среднесписочной численности работников.»;
б) части 7 – 9 признать утратившими силу;
в) часть 10 изложить в следующей редакции:
«10. Минимальное количество специальных рабочих мест для трудоустройства инвалидов устанавливается в пределах квоты для приема на работу инвалидов в соответствии с положением, утверждаемым Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

2) часть 1 статьи 5 изложить в следующей редакции:

«1. Работодателями резервируются рабочие места для трудоустройства граждан, особо нуждающихся в социальной защите, количество которых устанавливается уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области труда и занятости.»;

3) в части 2 статьи 6:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) выполнить квоту для приема на работу инвалидов, резервировать рабочие места по профессиям, наиболее подходящим для трудоустройства инвалидов, а также для трудоустройства граждан, особо нуждающихся в социальной защите;»;

б) в пункте $2^{1}$ слова «установленной Кабинетом Министров Республики Татарстан» заменить словами «установленной уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области труда и занятости».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Подпункты «а» и «б» пункта 1 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 сентября 2022 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 июля 2022 года
№ 47-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 14 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Инвалидларны эшкә алу өчен квота Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр өчен түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:
1) хезмәткәрләренең саны 35 кешедән алып 100 кешегә кадәр булган, 100 кешене кертеп, эш бирүчеләргә – хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача санынннан 2 процент күләмендә;
2) хезмәткәрләренең саны 100 кешедән артык булган эш бирүчеләргә – хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача санынннан 3 процент күләмендә билгеләнә.»;
б) 7 – 9 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;
в) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«10. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь саны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып, инвалидларны эшкә алу өчен квота чикләрендә билгеләнә.»;

2) 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эш

бирүчеләр тарафыннан эш урыннары резервлана, аларның саны Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.»;

3) 6 статьяның 2 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәргә, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен иң туры килә торган һөнәрләр буенча, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын резервларга;»;

б) $2^1$ пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 июль
№ 47-ТРЗ